# ЯЗУЧЫ ШАҺИНУР МОСТАФИННЫҢ РЕСПУБЛИКАНЫҢ РУХИ-МӘДӘНИ ТОРМЫШЫНА КЕРТКӘН ӨЛЕШЕ

*Әхмәтшина Ф. Ә.*

# CONTRIBUTION OF THE WRITER SHAGINUR MUSTAFIN TO THE SPIRITUAL AND CULTURAL LIFE OF THE REPUBLIC

*Akhmetshina F. A.*



«Татарстан Республикасы торак пунктлары: иллюстрацияле энциклопедия» китабының икенче томын әзерләгәндә, Мамадыш районында туган язучы Шаһинур Сафа улы Мостафинга үзе турында мәгълүмат бирүен үтенеп мөрәҗәгать иткән идек. Ул безгә үз култамгасы белән «Ш. С. Мостафинның тормыш юлы һәм иҗаты турында кыскача белешмә» алып килде (хәзер Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институтында саклана). Кызганыч, бер елдан язучының вафат булуы турында ишеттек. 2023 елның 12 февралендә танылган язучы, ватанпәрвәрлек темасын үстерүгә аеруча нәтиҗәле хезмәт куйган Шаһинур Мостафинга 75 яшь тулган булыр иде. Шул уңайдан, әдип үзе төзегән белешмәгә таянып, аның республиканың рухи-мәдәни тормышына керткән өлеше турында мәгълүмат бирү зарур дип табылды.

Язучы, прозаик һәм публицист Шаһинур Сафа улы Мостафин (әдәби тәхәллүсе – Шаһинур Әхмәтсафа) 1948 елның 12 февралендә Татарстанның Мамадыш районы Арташ авылында туа. 1966 елда Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегенә укырга керә, ике елдан читтән торып уку бүлегенә күчеп, уку йортын 1972 елда тәмамлый.

1963–1966 елларда авыл мәдәният йортында киномеханик ярдәмчесе, 1968 елдан Мамадыш, Кукмара район газеталары редакцияләрендә эшли. 1972–1973 елларда, Германиядә совет гаскәрләре группасында хезмәт иткән вакытта, «Совет Арми-

ясе» газетасы хәрби корреспонденты була, «Солдат сүзе» яшь хәрби корреспондентлар клубын җитәкли. 1973–1983 елларда Кукмара район газетасы редакциясендә хатлар бүлеген алып бара, биредә «Аһәңле сүз» әдәби клубы, соңрак республикада иң яхшылардан саналган иҗади берләшмә – «Салават күперен» оештыручы һәм җитәкчесе була.

1983–1988 елларда Ш. Мостафин – Татарстан Мәдәният министрлыгының халык иҗаты һәм мәдәният-мәгариф эшләренең фәнни-методик үзәгендә баш мөхәррир, 1988–1992 елларда – СССР, соңрак РСФСР Әдәбият фондының Татарстан бүлеге директоры, 1992–1999 елларда «Казан утлары» журналының бүлек мөдире вазифаларын башкара[1]. 1999–2005 елларда – Язучылар берлеге рәисенең иҗат эшләре буенча урынбасары, 2006–2017 елларда «Сүз» китап нәшриятының баш мөхәррире булып эшли.

Шаһинур Мостафин укучыларга документаль проза остасы, талантлы публицист һәм шагыйрь буларак билгеле. Муса Җәлилгә багышланган беренче шигырен ул алтынчы сыйныфта укыганда яза. 1963 елдан аның шигырьләре «Яшь ленинчы», «Татарстан яшьләре» газеталары битләрендә даими күренә башлый. 1965–1966 елларда Ш. Мостафин яшь шагыйрьләр һәм язучылар республика конкурсында җиңә. 1967 елда аның 8 шигыре Татар китап нәшриятында чыккан «Иркен минем туган илем» альманахында басыла.

1968 елдан башлап Ш. Мостафин Бөек Ватан сугышында эзсез югалган каһарманнарны эзләү белән шөгыльләнә. Ул бу игелекле эшкә үзенең ярты гасыр гомерен багышлый. Язучының әтисе Әхмәтсафа Мостафин Бөек Ватан сугышында исән калган 9 «матросовчы»ның берсе була[2]. 1943 елның 15 октябрендә Псков өлкәсенең Невель районы Горушки авылында хәрби бәрелешләр вакытында ул дошман дзоты амбразурасын күкрәге белән каплый. Үзе туфрак астына күмелеп кала, уң кулы күренеп торганлыктан, санитарлар аны табып ала. Әтисенең үтенече буенча, Шаһинур Мостафин Матросов батырлыгын кабатлаган сугышчылар турында мәгълүмат җыя башлый. Архивларда эзләнеп, Бөек Ватан сугышында 478 «матросовчы» сугышчы булуын, шуларның 26 сы милләттәш һәм якташларыбыз икәнен ачыклый[3]. Дистәләрчә еллар дәвамында Шаһинур Сафа улы эзтабарларның Татарстан Язучылар берлеге каршындагы «Хәтер яктысы» экспедициясе белән җитәкчелек итә[4]. Берлекнең башка әгъзалары белән бергә, сугыш булган бик күп урыннарга – Германия, Балтыйк буе, Кавказ республикаларына, Украинаның күп кенә төбәкләренә, Россиянең көнбатыш өлкәләренә экспедицияләр оештырып, яу кырларыннан кайтмый калганнарның, әлегә кадәр билгеле булмаган батырларның язмышларын архивларда ачыклый, каберләрен эзләп таба. Шаһинур Мостафин, сугыш ветераннары белән аралашып, алардан истәлекләр язып ала, шулай итеп үзенең язылачак әсәрләре өчен бай материал туплый. Егерме өч яшьлек талантлы яшь шагыйрь Мөхәммәт Әхмәтгалиевнең сугыш

алды көндәлекләре һәм фронттан җибәргән хатлары нигезендә иҗат ителгән «Әгәр кайта алмасам, онытмагыз...» (1996), Франциядә җәлилчеләрнең яшерен оешмасы җитәкчесе булган Әмир Үтәшев турында «Әманәт» (1996), сугышта сигез баласын югалткан Ана турында «Сигез бизәкле Сөлге» һәм башка бик күп документаль язмалары – аның игътибарга һәм ихтирамга лаек иҗат җимешләре. Әдипнең очерклары, документаль һәм публицистик язмалары республика газета-журналларында даими басыла; Татарстан китап нәшрияты чыгарган «Безнең Ангелиналар» (1981), «Ана бәхете» (1983), «Җирдәге йолдызлар» (1984), «Җиңү дәвам итә» (1985), «Көзге ачы җилләрдә» (1988), «Халык бәхете өчен көрәшүчеләр» (1989), «Мамадыш – яңарышта» (1989), «Җырларыбыз» (1989) һәм башка исемдәге күмәк җыентыкларда, китапларда урын ала. Ш. Мостафин катнашында нәшер ителгән «Батырлар Китабы» антологиясе (2000) «Ел китабы» исеменә, Кол Гали исемендәге Халыкара премиягә лаек була. «Васыять» (1995), «Хәтер яктысы» (2004), «Яңа меңъеллыкка очыш» (2008) әсәрләре Бөек Ватан сугышының исемнәре җуелып онытылган каһарманнарына багышлана. Бөек Җиңүнең 70 еллыгына Ш. Мостафинның «Ядрәләрне эреткән йөрәкләр» китабы дөнья күрә. Бу уникаль басма 2015 елда татар нәшриятларында басылып чыккан 365 китап арасында беренче урынны ала һәм «Ел китабы» исеменә лаек була. 2016 елда өч телдә дөнья күргән «Татарстанның фронтовик язучылары» антологиясен әзерләгәндә әдип татар телендәге басма авторы буларак актив катнаша. Антологияне төзүгә язучы Әхәт Мушинский, филология фәннәре кандидаты Р.Р. Мусабәкова үзләреннән зур өлеш кертәләр, Алексей Сахаров текстларны инглиз теленә тәрҗемә итә. 2017 елда Ш. Мостафин «Сүз» нәшриятында Муса Җәлил һәм Гайнан Кормашка багышланган «Алар – Җәлил-Кормаш йолдызлыгыннан!..» китабын бастыра. 2018 елда Татар китап нәшриятында язучының сугыш каһарманнары һәм тыл хезмәтчәннәренә багышланган чираттагы күләмле «Батырлык кайтавазы» китабы басылып чыга. Ш. Мостафинның хөрмәткә лаек җаваплы хезмәтенә дәлил буларак, исемнәре онытылган каһарманнарның туган җирләрендә мәһабәт һәйкәлләре урнаштырыла. Язучы батырларның исемнәрен мәктәпләргә, мәдәният йортларына, парк-скверларга бирү, документаль фильмнар эшләү буенча башлап йөри һәм бу эшкә киң җәмәгатьчелекнең дә игътибарын юнәлтә. Сергей Смирнов, Самат Шакир, Шамил Рәкыйпов, Рафаэль Мостафин кебек язучы эзтабарларның эшләрен бар күңелен, җан җылысын биреп дәвам итә.

Язучының зур әдәби хезмәте һәм җәмәгать эшчәнлеге, хаклы рәвештә, иҗат оешмаларының төрле бүләкләренә, халкыбыз ихтирамына лаек. 2007 елда Ш. Мостафин, эзтабарлык өлкәсендәге һәм иҗаттагы казанышлары өчен, Татарстанда яшәүче татар әдипләре арасында бердәнбер буларак, Россия Федерациясенең М. Ломоносов исемендәге премиясе һәм ал-

тын медаль белән, 70 еллык юбилеенда (2018 ел) Бөтендөнья татар конгрессының «Татар халкы алдындагы зур казанышлары өчен» медале белән бүләкләнә. Талантлы публицист Татарстан Журналистлар берлеге уздырган республика иҗат конкурсларында өч тапкыр җиңүгә ирешә: 1982 елда Хөсәен Ямашев исемендәге премия лауреаты, 2003 елда «Бәллүр каләм» бәйгесендә «Журналистикада абруйлы исем» номинациясе буенча, 2013 елда шул ук конкурста «Профессиягә тугрылык» номинациясе буенча лауреат була. 2005 елда Михаил Шолоховның 100 еллыгы уңаеннан Ш. Мостафинга Россия Федерациясенең «За гуманизм и служение России» медале, Муса Җәлилнең 100 һәм 110 еллыкларына юбилей медальләре тапшырыла. Шаһинур Мостафин 1999 елдан – Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре, 1995 елда – Татарстан Язучылар берлегенең Ш. Маннур исемендәге әдәби бүләге лауреаты. Татар әдәбиятын, мәдәниятен һәм сәнгатен үстерүгә зур өлеш керткән өчен Ш. Мостафин 2008 елда «Фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләнә. 2013 елда Россия хәрбитарихи фәннәр академиясенең һәм Петр I исемендәге Фән һәм сәнгать академиясенең мөхбир әгъзасы итеп сайлана. Санкт-Петербург шәһәрендә «Северная звезда» нәшриятында чыккан «Золотые имена России. Автобиблиографическая энциклопедия»дә Шаһинур Мостафин турында мәкалә һәм аның фотографиясе урнаштырылган. 2017 елда язучыга «Мамадыш шәһәренең мактаулы гражданы» исеме бирелә.

Ш.С. Мостафин 2020 елның 6 июнендә Казанда вафат була, туган авылында җирләнә.

**Сведения об авторе:** Ахметшина Флера Анасовна, научный сотрудник Центра регионоведения и социокультурных исследований Института Татарской энциклопедии и регионоведения Академии наук РТ, e-mail: flera-ah@mail.ru.

**Аннотация.** Статья посвящена жизненному пути и творчеству уроженца Мамадышского района писателя Шагинура Ахметсафовича Мустафина. Основное внимание уделено деятельности Ш. Мустафина в области поиска неизвестных героев, погибших на фронтах Великой Отечественной войны и увековечения их памяти.

**Ключевые слова:** Шагинур Мустафин, конкурс журналистов «Хрустальное перо», поисковая деятельность, подвиг Александра Матросова, международная премия им. Кул Гали.

**Abstract.** The article is devoted to the life path and work of the writer Shaginur Akhmetsafovich Mustafin, a native of the Mamadysh region. The main attention is paid to the activities of Sh. Mustafin in the field of searching for unknown heroes who died on the fronts of the Great Patriotic War and perpetuating their memory.

**Key words:** Shaginur Mustafin, biography, competition of journalists «Crystal Pen», search activity, feat of Alexander Matrosov, international award named after Kul Gali.

## ИСТОЧНИКИ И ЛИТЕРАТУРА

1 Әдипләребез. Биобиблиографик белешмәлек. 2 т. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2009. – 127 б.
2 Мостафин Ш.С. Батырлык кайтавазы. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2018. – 266–267 б.
3 Шәрәфиев Р. Күңелеңдә күпме җылылык бар... // Казан утлары. – 2008. – № 2. – 183 б.
4 Татар энциклопедиясе: 6 томда / Баш мөхәррир Ә.М. Мазһаров, җаваплы мөхәррир г.С. Сабирҗанов. – Казан: ТР ФАнең Татар энциклопедиясе институты, 2014. – 4 т.: М–П. – 248 б.